**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА ЛАИШЕВО**

ул. Коммунальная,
д.3,г.Лаишево,422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Коммунальная ур., 3 нче йорт,
Лаеш ш.,422610

тел: 8-(84378) -2-57-77, факс: 8-(84378) -2-50-62, e-mail:Gorod.La@tatar.ru

**2020 елның 5 августы** **42 номер**

# КАРАР

«Индивидуаль торак йорт» капиталь төзелеш объектын төзүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Салахиева Гөлнур Әлтәф кызының «Индивидуаль торак йорт» капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гаризасын карап, Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәрендә яшәүчеләрнең рөхсәт ителгән капиталь төзелеш объектын төзүнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләләре буенча фикер алышуда катнашу өчен хокукларын үтәү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 40 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәрендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре адресы буенча урнашкан, кадастр номеры -16:24:170151:24, мәйданы 1196 кв.м булган җир участогы өчен «индивидуаль торак йорт» капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча Лаеш шәһәре гражданнары катнашында ачык тыңлаулар үткәрергә. Милек хокукы Татарстан Республикасы буенча Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2014елның 7 ноябрендәге 16-73/018/2014-309 номерлы көнбатыш яктан 3 метрдан 1,2 метрга кадәр төзелеш рөхсәт ителә торган зонаны киметү өлешендә теркәлгән.

2. Гавами тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Лаеш муниципаль районының башкарма комитеты җитәкчесе тора.

3. Назначить проведение публичных слушаний по вопросу, указанному в пункте 1 настоящего постановления, и определить:

3.1 үткәрү датасы һәм вакыты - 2020 елның 07 сентябрендә 15.30 сәгатьтә.;

3.2. үткәрү срогы - 1 көн;

3.3. Үткәрү урыны - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Чернышевский урамы, 23 й. адресы буенча урнашкан Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының административ бинасы.

3.4. фикер алыша торган мәсьәлә буенча кисәтүләр, гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар өчен тәкъдим ителгән адрес - ТР, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, Коммуналь урамы, 3 йорт, Лаеш шәһәре башкарма комитеты- эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр. (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.).

4. Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре башкарма комитетына:

4.1. «Индивидуаль торак йорт» капиталь төзелеш объектының рөхсәт ителгән иң чик параметрларыннан гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда читкә тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4.2. Гражданка Салахиева Г.А. белән берлектә, әлеге карарны бастырып чыгарган көннең иртәгесеннән башлап Лаеш шәһәре Башкарма комитетының административ бинасында (адресы - Лаеш шәһ., Коммуналь ур., 3) гавами тыңлаулар предметы буенча документлар белән таныштыру мөмкинлеген тәэмин итәргә.

5.Әлеге карарны «Кама-Ягы» («Камская Новь») район газетасында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **В.А. Арефьев**